ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

21 02 2020 г. № 105

Кайбер муниципаль хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Советының 2020 елның 3 февралендәге 3 номерлы «Җирле мәсьәләләрне хәл итү буенча Түбән Кама муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы килешүләрне раслау турында» карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Афанас авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 23 гыйнварындагы 2а номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 23 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 23 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнва

рындагы 4 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 7 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 4а номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 27 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектларына адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.5. пунктын төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 21 июлендәге 1204 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.3.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.7 Мәгариф оешмалары «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат һәм документларның ачыклыгын һәм үтемлелеген тәэмин итә».

3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 гыйнварындагы 8 номерлы карары белән расланган урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны яшәү өчен яраксыз һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.5. пунктының 5 пунктчасында «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасында «проект-эзләнү» сүзен «махсуслаштырылган» сүзенә алмаштырырга.

4. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 12 ноябрендәге 2201 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Оешма «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән документлар белән керүче һәм (яки) аның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) таныштырырга тиеш.»;

9.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.4. Оешмалар «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат һәм документларның ачыклыгын һәм үтемле булуын тәэмин итәләр.

5. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган

муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буенча уза торган маршрутлар буенча автомобильдә авыр йөкләр, зур габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (23-нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.4. пунктның 9 абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 10 гыйнварындагы 1 номерлы «Түбән Кама муниципаль районының торак пунктлары чикләрендә урнашкан. алар турында белешмәләр аэронавигацион мәгълүмат документларында басылып чыкмаган мәйданнарда авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының демонстрацион очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очуын, бәйләнгән аэростатлар күтәрүне, утыртуны (очып китүне) башкару өчен рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 1 пункты исемендә, административ регламентның «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләпләрнең эчтәлеге» баганасының 1.1 пункты, 2.1, 2.3, 2.5, 2.7 пунктлары исемендә, административ регламентка 1-6 кушымталарында «пилотсыз очу аппаратлары очышлары» сүзләрен «пилотсыз һава судноларының очышлары (максималь күтәрелү массасы 0,25 килограммнан ким булган пилотсыз һава судноларының очышларыннан тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

административ регламентның 1.7. пунктындагы «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

7. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874